КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 25 май г.Казань № б-1078

Үз илебезнең яхта индустриясен һәм су туризмын үстерү һәм җирле яхталар һәм катерлар җитештерүчеләргә ярдәм күрсәтү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2026 елның 3 – 5 июлендә «Локомотив» ярымутравында урнашкан «Призма» яхта клубы территориясендә «Kazan Yachting Festival» яхта фестивален (алга таба – Фестиваль) оештыру һәм уздыру турындагы тәкъдимнәрен кабул итәргә.

2. «Kazan Yachting Festival» яхта фестивален әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетын төзергә һәм аның составын (боерыкка теркәлә) расларга.

3. Республика башкарма хакимият органнарына Фестивальне әзерләүдә һәм үткәрүдә оештыручыларга ярдәм күрсәтергә, шулай ук «Татарстан Республикасы Сәнәгать кластеры» ассоциациясенә һәм Татарстан Республикасының суднолар төзү тармагы оешмаларына – ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

4. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә Фестиваль уздырыла торган территориядә янгын куркынычсызлыгы таләпләре үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең Азсыешлы суднолар буенча дәүләт инспекциясенә Фестиваль уздырыла торган акваториядә аз сыешлы суднолар файдалануны, аларны эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм су объектларында иминлек таләпләре үтәлешен контрольдә тотуны оештыруны тәкъдим итәргә.

6. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

«Призма» яхта клубы янындагы территориядә чаралар оештыруда оештыручыларга булышлык күрсәтүне;

чара уздырыла торган көннәрдә «Призма» яхта клубы янындагы территориядә автомобиль транспорты өчен Протопоп Аввакум урамы буенча автомобиль юлын ябып торуны оештыруны;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында массакүләм чаралар уздырганда җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 ел, 24 гыйнвар, 42 нче карары таләпләре нигезендә Фестиваль уздырыла торган урыннарда иминлек инфраструктурасын тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына Фестиваль уздырыла торган урыннарда гражданнар иминлеген һәм җәмәгать тәртибен Россия Федерациясе законнары нигезендә тәэмин итүдә оештыручыларга булышлык күрсәтүне тәкъдим итәргә.

8. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Фестивальне мәгълүмати яктыртуда оештыручыларга ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

9. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 25 май, б-1078 нче
боерыгы белән расланды

«Kazan Yachting Festival» яхта фестивален әзерләү һәм
уздыру буенча оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Коробченко Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, оештыру комитеты рәисе |
| Колчин Иван Петрович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Степанов Владимир Николаевич | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының оборона комплексы бүлеге башлыгы, оештыру комитеты секретаре |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Арсланов Ринат Хәмзә улы | «Призма» яхта клубы хуҗасы (килешү буенча) |
| Глотов Дмитрий Александрович | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге башлыгы |
| Еремин Илья Олегович | Россия кластерлары эшлекле берләшмәсенең «Суднолар төзү» тармак комитеты координаторы (килешү буенча) |
| Майоров Сергей Васильевич | Россия кластерлары эшлекле берләшмәсе идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Макаров Дмитрий Александрович | «Kazan Yachting Festival» яхталар һәм катерлар күргәзмәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мокеев Денис Валерьевич | Россия Федерациясенең Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү буенча Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең Азсыешлы суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Казан инспекторлык бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Прытков Евгений Александрович | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Шакиров Илдар Сәетҗан улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесенең транспорт, икътисадый үсеш һәм сәүдә мәсьәләләре буенча урынбасары (килешү буенча). |